РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬКЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
422870, С.Базарные Матаки,
ул.С.Крайнова,д.56

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛКИ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
422870, РТ Базарлы Матак авылы,
С.Крайнов ур.,56

Телефон: (84346) 20-0-26, факс: (84346) 21-7-60. E-mail: alkay@tatar.ru, сайт: www.alkeevskiy.tatarstan.ru.

## ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2019 нчы елның 22 нче мае 206№

Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының
2018 нче елның 7 нче декабрендәге 460 номерлы
"Административ хокук бозулар турында беркетмәләр
төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеге"
Карарына үзгәрешләр кертү турында

2018 нче елның 19 нчы мартындагы 14-ТРЗ номерлы "Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында" Татарстан Республикасы Законы һәм "Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында " Татарстан Республикасы Законының 1 статьясы нигезендә, Әлки муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Административ хокук бозулар турында кодексының 2.15 статьясындагы 2 өлешендә каралган административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә - террорчылыкны профилактикалау, аның күренешләренең нәтиҗәләрен минимальләштерү һәм (яки) бетерү буенча коллегиаль орган карарын, административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 20.25 статьясындагы 1 өлешенең-үтәлмәвен яисә бозылуын, административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 20.25 статьясындагы 1 өлеше, Административ җәза үтәүдән читләшү, 2.4-2.8, 2.14, 3.2-3.7, 3.10,3.14-3.17,4.4,5.1,5.2,5.6, административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы Кодексының 5.4 статьясындагы 1 өлеше,19.5 статьясындагы 1 өлеше, Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе Кодексының 19.7 статьясы нигезендә үз компетенциясе кысаларында

Административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләргә.

2. Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 нче елның 7 нче декабрендәге 460 номерлы “Административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеге турында” карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затларга хисап кварталыннан соң килә торган айның 10 числосына кадәр җирле үзидарә органнарына тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турында хисап бирүне тәэмин итәргә, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органына билгеләнгән форма буенча тапшырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының эшләр идарәчесе Е. В. Бохаровага тапшырырга.

Әлки муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Йосыпов И.В.